ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

27.01.2026 № 90

«2025/2026 елларда Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларында башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү программаларын үзләштерүче гомуми белем бирү оешмалары укучыларын тукландыруны оештыру турында» 2025 елның 04 сентябрендәге 986 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 79 статьясындагы 7 өлеше нигезендә Нурлат муниципаль районының гомуми белем бирү оешмаларында балаларны социаль яклау, аларның сәламәтлеген саклау, баланслы кайнар туклану нормаларын үтәүне тәэмин итү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт мәгариф оешмаларында башлангыч гомуми белемнең уку-укыту программалары буенча укучыларны түләүсез кайнар туклану белән тәэмин итүгә 2026 елга, 2027 һәм 2028 еллар план чорына норматив чыгымнарны һәм башлангыч гомуми белемнең уку-укыту программалары буенча бер укучыга кайнар туклануның уртача бәясен раслау турында» 2025 елның 22 сентябрендәге 726 номерлы карары белән, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2026 елга, 2027 һәм 2028 еллар план чорына муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү программалары буенча укучыларны туклану белән тәэмин итү бәясе нормативын раслау турында» 2025 елның 3 октябрендәге 787 номерлы карары белән, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларының өстәмә социаль ярдәмгә мохтаҗ укучыларын туклану белән тәэмин итү турында» 2023 елның 16 гыйнварындагы 21 номерлы карары белән расланган (2023 елның 07 июлендәге 689 номерлы, 2024 елның 13 февралендәге 172 номерлы, 2025 елның 29 июлендәге 828 номерлы, 2025 елның 20 ноябрендәге 1334 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән),

Нурлат муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларында өстәмә социаль ярдәмгә мохтаҗ укучыларны тукландыруны оештыру тәртибе турында нигезләмәгә таянып, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. «2025/2026 елларда Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларында башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирүнең уку-укыту программаларын үзләштерүче гомуми белем бирү оешмалары укучыларын тукландыруны оештыру турында» 2025 елның 04 сентябрендәге 986 номерлы карарына (2025 елның 22 октябрендәге 1181 номерлы, 2025 елның 21 ноябрендәге 1352 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктның 1.1 – 1.9 пунктчаларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының гомуми белем бирү оешмаларында башлангыч гомуми белемнең уку-укыту программалары буенча укучыларны уртача бәясе 77,76 сум булган кайнар туклandыруны оештырырга.

1.2. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларында төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү программалары буенча укучыларны һәр уку көненә 10 сум 70 тиен күләмендә субсидиядән һәм ата-аналар түләвеннән торган суммага 74 сум 77 тиен күләмендә кайнар туклandыруны оештырырга.

1.3. Сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән укучыларны (ОВЗ) ике тапкыр түләүсез туклandыруны оештырырга, шул исәптән субсидияне исәпкә алып һәм җирле бюджет акчалары исәбеннән:

1-4 классларда бәясе 77 сум 76 тиен булган;

5-11 классларда бәясе 77 сум 76 тиен.

1.4. Ата-аналары яисә законлы вәкилләре махсус хәрби операциядә катнашкан гомуми белем бирү учреждениеләре укучылары өчен, шул исәптән субсидияләрне исәпкә алып һәм җирле бюджет акчалары исәбеннән, 2 тапкыр түләүсез туклану оештырырга:

1-4 классларда бәясе 77 сум 76 тиен булган;

5-11 классларда бәясе 77 сум 76 тиен.

1.5. 1.5 пунктчасы үз көчен югалткан дип танырга.

1.6. Нурлат муниципаль районы шәһәр гомуми белем бирү учреждениеләрендә озайтылган көн төркеменә йөрүче башлангычта 1-4 сыйныфта гомуми белем алучы бер укучыга исәпләнгән өстәмә туклану өчен һәр уку көненә 44 сум 23 тиен күләмендә кайнар туклану оештырырга.

1.7. Социаль якланмаган гаиләләрдәге балаларга адреслы социаль ярдәм күрсәтү максатларында Нурлат муниципаль районы гомуми белем бирү учреждениеләренә гариза нигезендә (1 нче кушымта) туклану өчен ата-ана кертемнәрен түләүдән азат итәргә һәм 2025 елның 01 сентябреннән кайнар

туклану белән тәэмин итәргә:

- махсус хәрби операциядә (СВО) катнашучыларның, шул исәптән һәлак булганнарның балалары;

- сәламәтлеге мөмкинлекләре чикләнгән, шул исәптән өйдә белем алучы укучылар;

- аз керемле гаиләләрдән укучылар;

- 3 һәм аннан күбрәк баласы булган аз керемле күпбалалы гаиләләрдән укучылар;

- инвалид балалары;

- ятим балалар;

- сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән 1-11 сыйныф укучылары, укулары өйдә оештырылган.

1.8. Сәламәтлеге мөмкинлекләре чикләнгән, шул исәптән өйдә белем алучы укучыларны ике тапкыр түләүсез туклану белән тәэмин итәргә.

1.9. Өйдә белем алучы сәламәтлеге мөмкинлекләре чикләнгән укучылар өчен ике тапкыр Түләүсез туклануны тәкъдим ителгән үрнәк буенча ОВЗ белән укучыга акчалата компенсация белән алмаштыру турындагы гариза нигезендә уку көннәре өчен акчалата компенсация белән алмаштыру мөмкинлеген тәэмин итәргә (2 нче кушымта).».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә) һәм Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2026 елның 01 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче Ә.К. Габдуллин